Бикбау кызы Зөләйха бәете

Татарлар арасында югары катлауның руслар белән катнашып әхлаксыз эшләрдән тыела алмый башлавы, 1830нчы еллар арасында язуга беркетелгән бер «Илаһи бәет»тә чагыла.

Бәет Казакъстанда, Алматы шәһәрендәге, Казакъстан ССР Фәннәр академиясенең М. Ауэзов исемендәге әдәбият институтының сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә сакланучы «№ 218» шифрлы кулъязмадан алынды.

Әлеге кулъязма 1946нче елны Чимкәнт шәһәрендә 200 сумга сатып алынган, катыргы тышлы, гадәти татар кулъязмасы кебек 17х22 см зурлыктагы форматта. Кулъязманың 1-51нче битләрендә XVII гасыр әдәбиятыбыз ядкаре «Фаслы дастаны нәсле Чыңгыз хан» һәм тагын бер зур гына фарсы телендәге әсәр бирелгән.

Чыңгыз хан дастаны ахырында «Илаһи бәет» тексты язылган. Без әлеге бәетне 1981нче елны Алматыда булган вакытыбызда күчереп алган идек.

Илаһи бәет

Бикбау байның коесы, үзе тирән — суы юк,
ай-вай, ни кылаем,
Бикбау кызы Зөләйха, үзе галим, гаклы юк,
ай-вай, ни кылаем.
Зөләйха кайда — бакчада, китабы кайда — букчада,
ай-вай, ни кылаем,
Зөләйха кебек тал-чыбык, сачыб йитмәс бакчада,
ай-вай, ни кылаем.
Унике сумлык сач бавыңны имди бирерсең кемгә
ай-вай, ни кылаем.
Зөләйханың әнкәсе кайгусындин катгандыр,
ай-вай, ни кылаем.
Урыс булып киткәндин соң, инде сине димәмдер,
ай-вай, ни кылаем.
Әткәемнең өендә, челтәрлүдер шүрлеге,
ай-вай, ни кылаем,
Җөмлә халык арасында булдым оят-хурлыгы,
ай-вай, ни кылаем.
Әткәемнең лә кигәне лә, хәтфә бүрек, кеш булыр,
ай-вай, ни кылаем.
Әткәемнең өендә уйнадым да, көлдем дә,
ай-вай, ни кылаем,

Әткәем өендән чыккач, югалдым да, булдым да,
ай-вай, ни кылаем.
Күб үк маллар да бетердем, кызымның башын саклап,
ай-вай, ни кылаем,
Уйнаганда, көлгәндә бик усал икәндер,
ай-вай, ни кылаем.
Әнкәемне ташлап киткән, бик усал икәндер,
ай-вай, ни кылаем,
Бозык-төзек әйберемне имди кемгә бирәем,
ай-вай, ни кылаем.
Әнкәем минем хәлем син сорама, мин әйтмәм,
ай-вай, ни кылаем.
Симез калҗа бешердем, аны ничек суытаем,
ай-вай, ни кылаем,
Кулымда тотып оттырдым, аны ничек онтаем,
ай-вай, ни кылаем.
Пәстә[*] төшкән ямщиккә, калага яллап күндердем,
ай-вай, ни кылаем...

Тагы җиде юл язу тәмам бозылып укымаслык хәлгә килгән, соңгы юлда гына:

Бикбау кызы Зөләйха ...
ай-вай, ни кылаем

дигән сүзләр белән бетә.

Әлеге бәетне басмага хәзерләгәндә безгә аның нинди вакыйгага мөнәсәбәте белән, кайда, кайсы елда язылганы бик үк ачык түгел иде.

Соңгы вакытларда архив материаллары белән танышып утырганда, бу бәетнең ни сәбәптән һәм кайчан язылган булуын ачкан бер мәгълүмат табылды. Татар әдәбиятының зур тарихчысы Гали Рәхимнең язмаларында бу темага кагылышлы түбәндәге хәбәр сакланып калган икән:

Ул хәбәрне бүгенге көндә, Әтнә районына керүче Олы Мәңгәр авылында яшәгән тарихчы Сафкол Котый улы (1757-1835) тарихыннан, Гали Рәхимгә күчереп җибәргәннәр:

«1776нчы йылда зөлхиҗҗәнең 14, дүшәмбе көн, Газан бистәсенең Яңа Галан Бикбау кызы Зөләйха асрау кызлары, бер ялчысы илән мөртәд улдылар. Әгузе билләһи...»[**].

Бу кыска гына хәбәр бәеттәге вакыйгаларның төгәл вакытын, булган урынын, конкрет рәвештә бәеттә искә алынган кешеләрнең кемлеген ачып бирә. Шуның белән берәттән, татар поэзиясенең XVIII гасырда конкрет чынбарлык белән яшәвенә өстәмә бер дәлил бирә. Бәетнең әдәбиятыбыз өчен генә түгел, Казан тарихы, социаль-иҗтимагый, дини мөнәсәбәтләрне ачыклау өчен дә кыйммәте бар.

«Бикбау кызы Зөләйха» бәетендә әхлаксызлыкның халык тарафыннан кискен гаепләнүе, аның Зөләйха өчен бәхетсезлек булуы, — дип кабул ителә. Ихтимал, бу бәет Гаяз Исхакыйга да мәгълүм булып, ул үзенең шул исемдәге драмасында, Бикбау кызының язмышы ни белән беткәнен күрсәтергә теләгәндер.

«Бикбау кызы Зөләйха» әсәренең тексты тулы түгел, ләкин эзләнүләр вакытында аның тулы нөсхәсе дә табылырга мөмкин.

Марсель Әхмәтҗанов,
филология фәннәре докторы

РЕЗЮМЕ
Доктор филологических наук М. И. Ахметзянов представляет ранее не опубликованный баит о Зулейхе, исследует историю появления этого литературного произведения.

* Пәстә — хурлык.
** Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсе, 18 ф., 1 тасвир., 6 сакл. бер., 58 б.